


## *Зарипова Хәдичә Баhаветдин кызы*

*Мин, Зарипова Хәдичә Баhаветдин кызы, 1929 нчы елның 10 нчы сентябренда туганмын. Ювас мәктәбендә укып, 3 класс белем алдым.*

*Сугыш башлангач, әтием сугышка китте hәм бәхеткә каршы, исән-сау әйләнеп кайтты.*

*Үзем гомер буе фермада эшләдем. Алдынгы урыннарда булдым. 9 бала тәрбияләп үстердем. 16 оныгым бар. Мин хәзерге вакытта улым Айрат гаиләсендә яшим. «Хезмәт ветераны» дигән таныклыгым бар. Сугыш вакытында ашарга юк иде, Кузгалак, күкәрин, кычыткан ашадык, эшкә ашамыйча да чыгып киткән вакытлар булды. Медальләрем дә бик куп. Сугышны елап каршыладык. Сугыш башлангач, әтием сугышка китте hәм бәхеткә каршы исән-сау әйләнеп кайтты. Сугышчыларга ярдәм жибәрмәдек, ул вакытта бер тиен дә акча юк иде. Сугыш бетүен бик шатланып каршы алдык. Хәзерге яшь буыннарга бәхет, шатлык телим. Сугышлар булмасын.*